**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Аксар авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**30.05.2022ел** **№61**

**«Аксар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 15 ноябрендәге 179 номерлы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 01 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Советының 2014елның 15 ноябрендәге 179 номерлы карары белән расланган (2021 елның 28 июлендәге 37 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәреш белән) «Аксар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук муниципаль хезмәткәрләртарафыннанкеремнәр, чыгымнар, мөлкәтһәммөлкәтихарактердагыйөкләмәләртурындабелешмәләрбирүхакында нигезләмәнең 6 пункты «в» пунктчасына, аннан «, акцияләр» сүзен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлек торак пунктлары

территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет рәисе Ю.И.Гильманов